**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТУРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№7** **2020 елның 16 октябреннән**

Депутат Гафаров Рөстәм Исмәгыйль улына карата
җаваплылык чараларын куллану турында

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшне җайга салу буенча 2020 елның 9 сентябрендәге ПР-19 номерлы комиссия утырышы беркетмәсеннән һәм Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тотышына булган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтәләрне карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советы түбәндәгеләрне билгеләп үтә:

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлеге советы депутаты Гафаров Рөстәм Исмәгыйль улы үз вакытында “Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры” ДАССУ учреждениесендә дәвалануда булу сәбәпле, 2019 елгы керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмаган һәм сәламәтлек торышы буенча белешмәләр тапшыру өчен документлар җыярга физик мөмкинлекләре булмаган. Гафаров Рөстәм Исмәгыйль улыннан тиешле аңлатма язулары бар.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.3-1 пунктына таянып,

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Советының дүртенче чакырылыш 6 нчы Турай бермандатлы сайлау округы буенча сайланган депутат Гафаров Рөстәм Исмәгыйль улын керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне вакытында тапшыру мөмкинлеге булмаганга күрә һәм авыру сәбәпле, шул исәптән «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә стационар дәвалануда булу сәбәпле, кисәтү рәвешендә җаваплылыкка тартырга.

2. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районының
Турай авыл җирлеге Советы Рәисе А.М.Рәхимова